РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 04 » 02 2021 г. № 64

Ютазы муниципаль районы территориясендә Россия Федерациясе Бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычлар булу (булмау) турында салым түләүчеләргә хәбәр итү эшен оештыру хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Советының 2020 елның 28 апрелендәге 18 номерлы карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, 2006 елның 12 гыйнварындагы 1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты турында Нигезләмә һәм Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте Идарәсенең һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының 22.01.20021 ел, № 21-21/5, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы белән үзара мәгълүмати хезмәттәшлек буенча Килешүне гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәләренә салым түләүчеләрнең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләре буенча бурычлар булу (булмау) турында мәгълүмат белән таныштыру эшен оештырырга.
2. Башкарма комитетының архив бүлегенә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының ЗАГС бүлегенә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлегенә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегенә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы

Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлегенә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының торак сәясәте бүлегенә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының муниципаль заказ буенча секторына, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторына, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесенә, « Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге" муниципаль казна учреждениесенә, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге» муниципаль казна учреждениесенә, Ютазы муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына, Ютазы муниципаль районы финанс-бюджет палатасына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 07.08.2012 ел, № 674 карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәткәндә һәм дәүләт функцияләрен үтәгәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек Тәртибе нигезендә, Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына ведомствоара мәгълүмати бәйләнешне оештыруга гарызнамәләр (заявкалар) җибәрүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм http://jutaza.tatarstan.ru/ Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында «Татарстан Республикасы Официальный” дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталында "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе С. П. Самонина

Р. М. Якупов
2-74-14